Хөснетдинова, Л. Дәвер моңын саклаучы: (Әлфия Ситдыйкова иҗатына күзәтү) / Л. Хөснетдинова // Мәдәни җомга. – 2022. – №29 (29 июль). – Б. 6.

Мәдәни җомга
29 июль
№29, 2022

Дәвер моңын саклаучы

(Әлфия Ситдыйкова иҗатына күзәтү)

Һәр язучы – үз иҗатында кабатланмас, үзенчәлекле шәхес. Ул чынбарлык күренешләрен үзенә генә хас хисләр һәм тойгылар, фикерләр белән сугара. Бу күренеш язучының тәрҗемәи хәле, рухи тәҗрибәсе белән бәйле. Әлфия Ситдыйкова иҗаты белән дә бу шулай. Г.Гыйльманов аны «кайнап торган тормыш, хәмһүш эченнән калыккан каләм иясе» дип бәяли, әдип Ф.Сафин да сүзен шушы ук рухта җиткерә.

Ә.Ситдыйкова Актаныш районы Күҗәкә авылында туа. Пучы урта мәктәбен тәмамлагач, Чаллыга килә. Шәһәрдә яңа төзелешләр чоры. Кызны яшьлек романтикасы чолгап ала. Эштән арып-талып кайтса да, каләмә белән хисләрен түгәргә җай таба. Шәһәрдә «Ләйсән» әдәби берләшмәсе барлыгын белеп алгач та, анда йөри башлый. Тик, тормышында сынаулар булып, иҗатын берара туктатып торырга туры килә. Хәер, аның каләме һәм зиһене тормыш фәлсәфәсендә үз фикерен җиткерергә «сүл туплап» торгандыр.

Үкенерлек түгел язмыш,
Бәхетлерәк күпләрдән.
Сыгылмый яшәр көч таптым
Тормыш салган йөкләрдән.

Бүгенге көндә Ә.Ситдыйкова поэзия һәм проза жанрларында уңышлы иҗат итә. Ф.Сафин «Офыгы киң, күге биек» мәкаләсендә аны «үз укучысын фикердәшенә әйләндерә алырлык серле шагыйрә» дип бәяләде. «Жанда кабынган учак» (2004, Яр Чаллы); «Утлы җимеш» (2011, ТКН);«Тансык бәхет»(2012, ТКН); «Яктылык сулышы» (2017, ТКН) җыентыкларында дөнья күргән һәм «Казан утлары», «Мәйдан», «Шоңкар», «Мәдәни җомга» кебек газета-журналларда даими басыла килгән лирик парчалары моңа инандыра.

Ә.Ситдыйкова поэзиясендә хис-тойгыларын жырлауда шәхси төсмерләр бар. Түбәндәге юлларда автор моны ул үзе бик ачык итеп тәүдәләндерә:

Үз максатым, үзем яулар үрем,
Үзем генә җырлар җырым бар.

Ә.Ситдыйкова тамырларының җир кешесеневе булуы белән чиксез горурлана һәм шуның белән үзен бәхетле саный:

Җирдә туып, җирдә үстем бит мин,
Җиргә бәйле бөтен язмышым.
Тамырларым илем туфрагында,
Тоеп яшим җирнең сулышын.

Лирик героеның хыял-омтылышлары гади җир кызыныкы: сөелеп-сөеп яшәү, туган җиргә, туган телгә мәхәббәтне, тугрылыкны саклау. Юкка гына халык шагыйре Р.Гаташ шагыйрәнең мәхәббәт лирикасын: «Син – халкың өчен тарихи әрнүләрне милли гамь касәсеннән даими эчеп тә, барыбер горур исемеңне саклап киләсең. Өстәвенә ир-атларның (шагыйрьләрне әйтүем) чуар йөрәген дә аңлап, хәтта аңа кушылып, бер җанга әверелеп, үз булып яши алу халәтенә ия бит син, Хауабыз таифәсе! Бу үзе үк, хатын-кыз дигән олуг затның матурлык белән бергә дөньяны саклау, яшәтү, дәвам итү миссиясе түгелмени?» – дип бәяләми.

Мәхәббәт лирикасында «мин» күңеленде мәңге бетмәс моң. Әмма лирик герой чын сөю барлыгына ышана, шушы хисне зурлый белә. Мәхәббәтендә югалтулар, хаталанулар булса да, ул бу хисләренә рәхмәтле. Чөнки күңеле нәкъ менә сөюдән илаһи бөеклеккә ашкына:

Хыял түгел, чынбарлыгым
Күтәрә бит өскә.
Сине күргәч аңладым мин –
Бәхет нинди төстә.

Шагыйрә кичерешләренең катлаулылыгын, нечкәлеген тормышчан, шушы хисләрдән туган ачык фикерләрен төгәл, нәфис сурәтләр белән житкерә:

«Кандыр мине!» – диеп кабатлыймын,
Тыңларсың дип куркa йөрәгем.

Ә.Ситдыйкова – көчле рухлы, максатчан шәхес. Ул югалтулар артыннан табышлар киләсенә ышана, өмет хисен сүндермәи. Аның бу сыйфаты һәр әсәрендә чагылыш таба.

Абынсаң да, нык бул, егылма.
Егылсаң да,шундук торып бас!
Учак як та, аннан казан ас.
Соклансыннар күреп үзеңне.
Бәхет баскан чаклар була аз.
Көен җуйган чакта моңлы саз,
Капламасын болыт йөзеңне!

Көчле кешеләр холкына хас күркәм сыйфат бар. Ул – тормышта язмышына, хәтта аның бик үк уңайлы булмаган борылышларына да шөкер итү. Ә.Ситдыйкова үзенә насыйп булган язмышны рәхмәтә белән кабул итә.

Рәхмәт, язмыш, каршылыклар белән
Сыныйсың син минем ныклыкны.
Жиңелү һәм жиңү барын аңлап,
Чыныктырып яшим холыкны.

Язучының рухи ныклык, әхлак турында уйланулары, идеаллары татарның гасырлардан килгән яшәеш кануннарына корылган. Әсәрләрдә татар образлы фикерләвенә хас булган образ-детальләр килешле итеп урын ала. Мәсәлән, автор табигать сурәтләрен кичерешләренә ялган жибәрү, киресенчә, хисләрне табигать сурәтләре белән тирәнәйтү алымын яратып куллана.

Мин сагынсам, болытларга карыйм,
Сәлам юллап синең тарафка...
Синнән килгән болыт эленеп калган
Өй янында үскән наратка.

Аның төслəр поэтикасыннан файдалану осталыгы белән сокландыра.

Язмышына әгәр язган булса сагыш,
Яба вакыт сары яулык алсу йөзгә.
Күңел күген күкселләтеп, болыт йөзә,
Аваз сала кара төндә әрсез байгыш.

Ә.Ситдыйкова ишарәләп, кинаяләп язучылардан түгел. Әсәрләрендә күңел халәте, жан хәрәкәте нәкъ менә гадилек, тормышчанлык, ихласлык белән йөрәк түренә барып тоташа. Бәлки шуңадыр да, авторның байтак шигырьләре көйгә салынган, жыр булып яңгырый.

Шагыйрә буларак, Ә.Ситдыйкова поэма жанрында да уңышлы иҗат итә. Аның дистәдән артык поэмасы бар. «Язмышлар ярында», «Буталган язмышлар», «Күмер базы», «Өммегөлсем», «Хәсән Заманов» кебек әсәрләре чорның, катлаулы язмышларның шигъри тел белән язылган документаль бәяннары булып тора.

Авторның сәяхәтнамә итеп язылган әсәрләре дә бар. Аларда автор тыңгысыз, эзләнүчән, кызыксынучан табигатьле зат буларак гәүдәләнеш ала. Авторга сәяхәтләр милли үзенчәлекләрне, тарихи үткәнне ныграк аңлау, гыйбрәт алу өчен бик тә файдалы, әмма:

Чит илләрдә кеше кунак кына,
Үз җирендә солтан, уйласаң.
Үз халкыңа, туган төбәгеңә
Кирәк булып яшәү – олы бәхет,
Әйләнгәндә дөнья-куласаң...

Язучы көннән-көн иҗат офыкларын киңәйтә, каләменең мөмкинлекләрен, ача, куәтен көчәйтә бара. 2019 елда аның күләмле тәүге проза әсәре – «Дөнья тәгәрмәче» повесте дөнья күрде. Аны укыгач, Ә.Ситдыйкова өчен шигърияттән прозага күчү дә берни тормагандыр сыман тәэсир кала. Сюжет вакыйгаларының тормышчанлыгы, документальлеге шуның белән аңлатыла. КАМАЗ тарихындагы байтак вакыйгаларның шаһиты булган һәм шуны күңеленә сеңдергән автор шул чор рухын тәгәл житкерә алган. Әсәрнең үзәк герое — Мәдинә, авторның үзе сыман, яшьлек чакыруына иярәп, зур төзелеш башланган шәһәргә килә. Автор бу образны барлык күңел байлыгын салып иҗат итә. Ул аңа зур идея – эстетик вазифа йөкли. Кеше хезмәттә үзенең асыл көчләрен тормышка ашыра. Геройның балачагы сурәтләреннән башлап, КАМАЗда хезмәт куя чорын тасвирлау шушы карап белән сугарылган. Шигъри жанрлы, хыялый кыз үзе кебек уртак яшьлек дәрте белән янган егет-кызлар янәшәсендә тырышып хезмәт куя. Бөтен ил башлаган төзелешкә үз өлешен кертү белән чиксез горурлана. Ә.Ситдыйкова гади генә хезмәт процессын да шагыйранә матур итеп сурәтли.

Автор Мәдинә образы аша «кешене өмет һәм мәхәббәт яшәта» дигән фикер сугара. Мәхәббәт – кешегә Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән ин зур бүләк ул. Яшь кеше ышаныч шушы бәхетне көтә. Мәдинәгә әлеге серле хисне татырга насыйп була. Әмма дөнья тәгәрмәче тигез юлдан гына бармый шул. Мәдинәгә дә хыянәт ачысын татырга туры килә. Ләкин кыз бирешми. Калебенә иҗатлык сәләте салынган кыз үзен алда кызыклы язмыш көтүенә, иҗаты белән дөньяга сафлык, садәлек өләшеп, бәхетле булачагына ышана.

Мәдинәнең балаларына мәхәббәте, мөнәсәбәте бүгенге яшьләр өчен үрнәк. Мәдинәгә балаларын ялгыз үстерергә туры килә. Көчле ихтыярлы хатын аларны жил-яңгыр тидермәи, үз канаты астында тәрбияли. Тормышының ин авыр вакытларында да рухи ныклыгын саклап калган Мәдинә укучы күңелендә соклану уята.

Ә.Ситдыйкова 2021 елда «Диңгез суы тозлы ул» романын төгәлләде. Әсәрнең исеме идея йөкләмәсе белән тыгыз бәйләнешле итеп сайланган. Диңгез сәнгатьтә дөньясында зурлыкны, олылыкны белдергән символ рәвешендә яңгырый. Әсәр нигездә дөньядагы барлык назны үз күңеленә сыйдырган, кешене жан җылысы белән йөрәкләрне җылытып яшәүче хатын кызларга багышланган. Романны ана мәхәббәтенә мәдхия, дип тә бәяләргә булыр иде. Әсәр биш кисәктән тора. Һәр кисәк бер гыйбрәтле вакыйга – хәлне бәян итә. Аларны гомуми тематика һәм идея берләштерә. Ана – кешелек дөньясын яшәтүче һәм яшәртүче зат. Аның күңеле тирән диңгез сыман. Баласының язмышында искән һәр җилгә диңгез сыман дулкынлана.

Китапта язмышлары бәян ителгән геройларның прототиплары бар, ләкин автор вакыйгаларны чынбарлык итеп кабул итмәүне үтенә. Геройлар – сәнгатьчә гомумиләштерелгән. Мондый язмышлы кешеләр һәр авылда бар.

Лилия ХӨСНЕТДИНОВА,
филология фәннәре кандидаты.